

Бөтендөнья балалары, дуслашыгыз!

Сабантуй

Балалар һәм үсмерләр газетасы

1 июль, 2000 ел.
N51
(5178)

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ



Мин - татар малаә!

Чатнатып сөйләшәм
Үз ана телемдә.
Оялмыйм, курыкмыйм, -
Мин бит үз илемдә!

Башымда - чигүле,
Каюлы түбәтәй.
Догалар укырга
Өйрәтә дәү әтәй.

Тәүфикълы булырга
Кирәген беләм мин.
Чын татар малае
Йөрәгем белән мин!

Өй җыештырдым

Әни кушкач, ә дигәнче
Өйне карап өлгердем.
Уенчыкларны җыйнадым,
Идәннәрне себердем.

Эш беткәч, уйнарга ярый,
Тагын уйный башладым, -
Бөтен булган уенчыкны
Кабат чәчеп ташладым.



Әйләнәбез

Минем бер шуклыгым өчен
Әни тиргәми.
Көне буе әйләнәм мин
Кояш тирәли.

Минем белән бергә оча
Энем Алмаз да.
Бер тамчы да курыкмыйбыз,
Хәтта аз-маз да...

Әнием дә, әтием дә,
Өй дә әйләнә.
Мин дә әйләним әле дип,
Акбай бәйләнә...

Инде күнегеп тә беттек
Гел әйләнергә.
Галәм буйлап әйләнәбез
Җир белән бергә!

Күчмәгән

Әти-әнисе Булатка
Өр-яңа чаңгы алган.
Чөнки былтыргы чаңгысы
Бөтенләй кыска калган.

Эче катып көлеп тора -
Булат әллә нишләгән:
«Узган ел йөргән чаңгым, ди,
Классыннан күчмәгән...»



Әнә -
Урамда бер багана,
Карап урман ягына,
Кош-
лар
Ке-
бек
Ка-
гы-
на.
Ул
ур-
ма-
нын
Са-
гы-
на.
Кайтыр
И-
де
Әй-
лә-
неп,
Ку-
ел-
ган
шул
Бәй-
лә-
неп...



Әтәчне кайчандыр
Күктән төшкән, диләр.
Хәтта кояштан ук
Җиргә күчкән, диләр.



«Күкри күк!» дигәне
Шуны аңлата, ди...
Ул бит: «Уяныгыз,
Күкрәп таң ата!» - ди.





КАЙТАВАЗ

Күккә карап киң яланда ятам,
Ап-ак болыт булып көн ага...
Әллә нидән генә, тик торганнан:
«Саумы!» - диеп дәштем дөньяга.

«Саумы-ы-ы...» - диеп җавап бирде кемдер,
Кем икәнен шәйләп калмадым.
Әллә инде җилләр исеп үтте,
Әллә җыры булды кылганның?

Тукта-тукта! Миңа җавап биргән -
Сандугачлы, таллы яр икән.
Әнкәй миңа гел дөресен әйткән -
Табигатьнең җаны бар икән!



Бер кеше күренми, әллә
Көтүчесе югалган? -
Көтү килә, ак сакаллы
Кәҗә килә иң алдан.

Бөтен авылның көтүен
Яланга алып чыккан.
Зур начальник булган
кәҗә
Галстук тагып чыккан.

Эт аталар

Төн. Караңгы. Каршы йортта
Утлар сүнә... Яталар.
Булат тәрәзәгә килгән, -
Урамда эт аталар.

«Шарт»та «шорт» мылтык тавышын
Этләр чинавы күмә.
Урамда җаннар кыела,
Урамда - канлы өмә.

Булат әле аңлый алмый,
Сизә генә әле ул...
Бер карасаң - тере кебек,
Бер карасаң - үле ул...

Кыймшанмый да карап тора,
Кыймшанырга курка ул.
Кеп-кечкенә күңелендә
Уйнап йөри зур давыл.

Кай җиредер авыртудан
Булат йөзләрен чытты.
Ул шулай бала чагының
Чикләрен атлап чыкты.



Көн дә барабан
таптыра,
Нишләгәндер
бу Рәсим?
Әнисе йөрәген
тоткан:
«Бар икән, ди,
күрәсем!..
Тавышыннан
колак тонар,
Белмим әле,
уйлармын...»
Рәсим әйтә:
«Ә мин аны
Син йоклагач
уйнармын...»

Көлү качмасын

Көннәр буе көлә Зилә,
Шундый көләч бер кыз ул.
Күп көлүдән йөзе алсу,
Колак очы кып-кызыл.

Көлгән чакта учы белән
Авызын каплап тора.
Очып чыгып китмәсен дип,
Көлүен саклап тора.

Сыерчык килде



Дәртле кагынып,
Сыерчык сайрый.
Үзенә шулай
Ул оя сайлый.

Берсен тирән ди,
Берсен бик сай ди,
Һәм... килеп, минем
Ояны сайлый.

Әйтә кебек ул
/Мин шулай тоям/:
- Якты һәм җылы
Ясаган ояң...

Нигә ул шулай
Якты, җылы соң?
- Мин аңа салдым
Күңел җылысын.

Җәй белән хушлашу

Бер чәчәк селкенми,
Бер куак кыймшанмый.
Бер серле тавыш бар -
Кем анда, кем чыңлый?..

Уйнамый, дуламый
Тынгысыз җәй-чаптар...
Елап җибәрер күк -
Күзендә... чык бар.

Бер болыт яшәгән, ди...



Бер болыт яшәгән, ди.
Кыш җитүгә бу болыт
Бик каты өшегән, ди.

Читкә китәргә булган,
Туган якның матурлыгы
Бөтенләй дә онтылган.

Юл тоткан, ди, көньякка,
Нурлы Кояш иленә
Мәңгелеккә кунакка.

Әмма бик тиз сагынган,
Яңадан кайтыр өчен
Җылы язга тагылган.

Илен бик тиз тапкан ул,
Сагынуына түзмичә,
Елый-елый кайткан ул.

Кайткан, җирне юешләп.
Аптырый, ди, чит җирдә
Йөргәндер ул ни эшләп?!

Безнең Светофор

Күрше-күләннең көн саен
Йомышы төшеп тора.
Яшел капкабыз һәркемне:
«Кер, кер!» - дип дәшеп тора.

Көн буена капкабыздан
Йөз кеше үтеп йөри.
Кемнәрдер туктап та тормый,
Кемдер җай көтеп йөри.

Һәркемнең усал этәче,
Ата казы, эте бар.
Чамалап керергә кирәк,
Керүнең дә рәте бар!

Бездә - бозау. Сөзеп ата,
Аз гына кыймылдасаң.
Сарбай исә бик тешләми,
Үзенә кагылмасаң...

Әйтерсең, безнең һәр җирдә
Светофорлар куелган.
Бозау - кызыл, Сарбай - сары,
Өй яшелгә буялган!

Мин чыдам

Быел тагын Дәү әнигә
Кунакка кайттык.
Кайтканнан бирле энемнең
Чырае чытык.

Сагына ул өйдә калган
Әти-әнине.
Ун мәртәбә, йөз мәртәбә
Елый көненә.

Ә мин...
Алай елап йөрмим.
Мин шундый чыдам!
Мин бит...
Караңгы чоланга
Еларга чыгам.



Курай



Курайда кырлар догасы,
Чишмә тавышлары бар.
Курайда туган як гаме,
Кеше сагышлары бар.


Иң элек курайда туа
Һәр аткан таңның көе.
Курай ул тылсымлы әйбер,
Курай ул - моңның көе!

Шомырт салкыннары

Ап-ак болытмыни -
Шомырт шау чәчәктә.
«Шомырт салкыннары»
Булыр киләчәктә.

Шулай кышның җаны
Салкын булып төшә.
Ак кар кебек, соңгы
Салкын болыт төшә.

Чишмәгә бардык




Чишмә суын мактый әби:
«Тәнгә бик шифалы», - ди. -
Самавырга җитми инде,
Кирәкми «Тифалы», - ди.

Бүген дә әбиебезгә
Чишмәдән су китердек.
Кайткан чакта чалбарларга
Түгеп-чәчеп бетердек...

Очраган бөтен кешегә
Әбидән сәлам әйттек.
... Бер чиләк су алып кайттык,
Бер чиләк - сәламәтлек!





Кызыл карлыган

Бик мактанчык бер карлыган
Бик иртә яфрак ярган.
Яшел төймәләрен тагып,
Базарга китеп барган.


Ләкин аны базар халкы
Бер дә сатып алмаган.
Һи, кешеләр каты, тәмсез
Карлыганга калмаган.

Тегe мактанчык карлыган
Кире кайткан базардан.
Бик тә оят булган аңа,
Оятыннан... кызарган!

Хәлим кул күтәрде

Өй эшен хәзерләми, дип,
Хәлимне орышалар.
Дәрестә кул күтәрми, дип,
Хурларга тырышалар.

Хәлимне мин әйбәт беләм,
Сөйләмәгез лә юкны! -
Әле генә Наиләгә
Кулын күтәреп... сукты!



Эт кояшы

Әни әйтә: «Бүген
Эт кояшы тышта.
Мондый салкын көннәр
Булмагандыр кыш та».

Күктә - нурлы кояш,
Канатлары - алтын!
Ә урамда - суык!
Ә урамда - салкын!

Тәрәзәгә килеп,
Карап тордым юри.
Бер кеше юк тышта,
Этләр генә йөри...

Караңгы төн


Көне көн булмады бүген,
Кап-караңгы урам.
Уйныйсы да килми хәтта,
Бер урында торам.

Кая булган бу Кояш, дип
Уйлыйм кайчагында.
Бөтен дөнья, бөтен авыл
Болыт ышыгында.

Агачларны юкә дисәм,
Ә ул каен икән...
Яктысыз, нурсыз, кояшсыз
Яшәү кыен икән...

Әллә Ай белән Кояшның
Урыннары күчкән?
Иртә таңнан бөтен җиргә
Караңгылык төшкән.

Ялварып сораган булам:
«Кояшкаем, чык!» - дим.
... Бүген мин тышка кап-кара
Күзлек киеп чыктым!



Мин зур инде, укыйм-язам,
Унга кадәр саный беләм.
Күбрәк тә санар идем,
Туктыйм унбер саны белән.

Бу санда хата бар кебек;
Ун берең нәкъ ун була бит.
Кабат саныйм, язып саныйм,
Яттан гына онтыла бит...

Ун ике - егерме була,
Ун өч - утыз, ун дүрт - кырык...
Ис-акылларың китәрлек,
Өлкәннәргә карап торып...

Беркемнән дә оялмыйча,
Илледән соң йөз диләр бит.
Илле икең йөз булганны
Уйлыйлармы сизмиләр дип?..

Аларча, ике илле бар,
Ике алтмыш, ике сиксән...
Бу ялган бер бетәр микән,
Меңгә, миллионнарга җитсәң?..

Юри санарга өйрәнмим,
Бу өлкәннәр - чи ялганчы,
Надан булу әйбәтрәк
Ялганчы булып калганчы.



Баш мөхәррир Ләлә ГЫЙМАДИЕВА.
Адрес: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Газета ТР Матбугат һәм информация министрлыгында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры 451.
"Идел-Пресс" полиграфия-нәшрияты комплексында басылды.
Заказ 20130.
Басарга кул куелды: 2000 ел, 29 июнь, 15 сәгать.